**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 24 апрель № 282

г. Казань

“Форпост” җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр формированиеләренең республика үзәге” дәүләт бюджет учреждениесен булдыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Дәүләт (муниципаль) учреждениеләренең хокукый хәлен камилләштерү белән бәйле Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2010 ел 8 май, 83-ФЗ номерлы Федераль законны Татарстан Республикасында тормышка ашыру чаралары хакында” 2010 ел, 18 октябрь, 820 нче карарын тормышка ашыру, яшьләрнең хокук саклау хәрәкәтен үстерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. “Форпост” җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр формированиеләренең республика үзәге” дәүләт бюджет учреждениесен (алга таба – Учреждение) булдыру турында Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы тәкъдимен кабул итәргә, аның эшчәнлегенең төп максаты итеп Татарстан Республикасында яшьләрнең хокук саклау хәрәкәтен үстерүне билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына:

Учреждениенең гамәлгә куючысы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен тормышка ашырырга;

утыз көн эчендә Учреждениенең уставын расларга һәм законнар нигезендә бүтән зарур оештыру чараларын тормышка ашырырга;

үз норматив хокукый актларын әлеге карарга яраштырырга;

Учреждение уставы расланганнан соң ун көн эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Учреждение эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте, шул исәптән аеруча кыйммәтле күчмә мөлкәт исемлеген тапшырырга;

ел саен уставында каралган эшчәнлегенең төп төре нигезендә Учреждение өчен дәүләт биремен расларга.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Учреждение уставы расланганнан соң билгеләнгән тәртиптә утыз көн эчендә элегрәк “Форпост” җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар)

формированиеләренең республика үзәге” автоном коммерциячел булмаган оешма карамагында булган Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен оператив идарә итү хокукында Учреждениегә беркетергә.

4. Учреждение тарафыннан дәүләт биремен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Дәүләт учреждениеләре һәм коммерциягә карамаган башка оешмалар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында” 2010 ел, 29 апрель, 308 нче карарында билгеләнгән тәртиптә, тиешле финанс елына һәм “Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы” ведомствосы буенча планлаштырылган чорга Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган чаралар кысаларында гамәлгә ашырыла.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\282.doc